**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 26 гыйнвар № 41

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне планлаштыру һәм мониторинглау буенча мәгълүмат ресурсын формалаштыруның бердәм ведомствоара системасы турында» 2012 ел, 20 октябрь, 890 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

«Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне планлаштыру һәм мониторинглау буенча мәгълүмат ресурсын формалаштыруның бердәм ведомствоара системасы турында» 2012 ел, 20 октябрь, 890 нчы (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 30 май, 361 нче, 2013 ел, 30 сентябрь, 701 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның исемендә һәм текст буенча тиешле саннардагы һәм килешләрдәге «учреждение» сүзен тиешле саннардагы һәм килешләрдәге «оешма» сүзенә алмаштырырга;

2 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне планлаштыру һәм мониторинглау буенча мәгълүмат ресурсын формалаштыруның бердәм ведомствоара системасында урнаштырылучы дәүләт оешмалары, муниципаль оешмалар тасвирнамәләрен, шулай ук муниципаль берәмлекләрнең тышкы төзекләндерү объектларын мониторинглау һәм аларга булышлык күрсәтү тәртибе турында нигезләмәне.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне планлаштыру һәм мониторинглау буенча мәгълүмат ресурсын формалаштыруның бердәм ведомствоара системасы турындагы нигезләмәдә:

исемендә һәм текст буенча тиешле саннардагы һәм килешләрдәге «учреждение» сүзен тиешле саннардагы һәм килешләрдәге «оешма» сүзенә алмаштырырга;

1.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«төзекләндерү паспорты – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм мәгълүмат ресурсына керә торган, җирле үзидарә органнары балансында булган (юллар, күперләр, зиратлар, яшел утыртмалар, урам яктырту объектлары, гидротехник корылмалар һәм башка объектлар) тышкы төзекләндерү объектлары турында бердәм нормага китерелгән электрон мәгълүмат.»;

3.1 пунктта:

түбәндәге эчтәлекле яңа алтынчы абзац өстәргә:

«төзекләндерү паспортларының мәгълүмат фонды»;

алтынчы – уникенче абзацларны тиешенчә җиденче – унөченче абзацлар дип санарга;

күрсәтелгән Нигезләмәгә 2 нче кушымтада түбәндәге эчтәлекле $4^1$ пункт өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «$4^1$. | Төзекләндерү паспортларының мәгълүмат фонды | бердәм ведомствоара системада катнашучы – тышкы төзекләндерү объектының баланс хуҗасы | бердәм ведомствоара системада катнашучы – тышкы төзекләндерү объектының баланс хуҗасы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, «Татарстан Республикасы ИСТҮ» ДБУ | тышкы төзекләндерү объектын кулланылышка керткән яки гамәлдәге тышкы төзекләндерү объектларының төп тасвирларын үзгәрткән көннән соң 30 көн эчендә»; |

Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне планлаштыру һәм мониторинглау буенча мәгълүмат ресурсын формалаштыруның бердәм ведомствоара системасында урнаштырылучы дәүләт, муниципаль учреждениеләр тасвирнамәләрен мониторинглау һәм аларга булышлык күрсәтү тәртибе турында нигезләмәне яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\41.docx

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 20 октябрь, 890 нчы карары белән расланды
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 26 гыйнвар, 41 нче карары редакциясендә)

**Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне планлаштыру һәм мониторинглау буенча мәгълүмат ресурсын формалаштыруның бердәм ведомствоара системасында урнаштырылучы дәүләт, муниципаль учреждениеләр тасвирнамәләрен мониторинглау һәм аларга булышлык күрсәтү тәртибе турында**

# НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне планлаштыру һәм мониторинглау буенча мәгълүмат ресурсын формалаштыруның бердәм ведомствоара системасы (алга таба – бердәм ведомствоара система) составында тасвирнамәләрне мониторинглау һәм аларга булышлык күрсәтү тәртибен регламентлаштыра:

а) гамәлдәге, яңа төзелгән, үзгәртеп төзелгән, шулай ук төрен үзгәртү юлы белән төзелгән бюджет, автоном, казна дәүләт һәм муниципаль учреждениеләрне (аерымланган структур бүлекчәләрне);

б) төзергә планлаштырылган бюджет, автоном, казна дәүләт һәм муниципаль учреждениеләрне (аерымланган структур бүлекчәләрне);

в) муниципаль берәмлекләрнең тышкы төзекләндерү объектларын.

1.2. Бердәм ведомствоара системада дәүләт һәм муниципаль оешмаларны (аерымланган структур бүлекчәләрне) мониторинглауны, аларга булышлык күрсәтүне түбәндәгеләр гамәлгә ашыра:

әлеге Нигезләмәнең 1.1 пунктындагы «а» һәм «б» ярдәмче пунктларында санап кителгән оешмалар өлешендә – яңа оешманы теркәгән яки гамәлдәге оешманың төп тасвирларын үзгәрткән көннән соң, эш көннәрендә исәпләнгән ун көн эчендә тиешле оешмаларның гамәлгә куючысы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен тормышка ашыручы органнар (алга таба – гамәлгә куючы) һәм «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – ИСТҮ);

муниципаль берәмлекләрнең тышкы төзекләндерү объектлары өлешендә –

тышкы төзекләндерү объектын кулланылышка керткән яки гамәлдәге тышкы төзекләндерү объектларының төп тасвирларын үзгәрткән көннән соң бер ай эчендә җирле үзидарә органнары.

## 2. ЯҢА ТӨЗЕЛГӘН, ҮЗГӘРТЕП ТӨЗЕЛГӘН, ШУЛАЙ УК ТӨРЕН ҮЗГӘРТҮ ЮЛЫ БЕЛӘН ТӨЗЕЛГӘН ДӘҮЛӘТ ҺӘМ МУНИЦИПАЛЬ УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРНЕҢ (АЕРЫМЛАНГАН СТРУКТУР БҮЛЕКЧӘЛӘРНЕҢ) ТАСВИРНАМӘЛӘРЕН УРНАШТЫРУ ТӘРТИБЕ

2.1. Яңа төзелгән, үзгәртеп төзелгән, шулай ук төрен үзгәртү юлы белән төзелгән оешманың (аерымланган структур бүлекчәнең) гамәлгә куючысы ИСТҮгә, ә муниципаль оешмалар буенча – шулай ук тармак министрлыгына (дәүләт комитетына, ведомствога) әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтага ярашлы рәвештә гомуми мәгълүматлар һәм дәүләт хакимияте органының, җирле үзидарә органының оешманы (аерымланган структур бүлекчәне) төзү, яңадан төзү, шулай ук төрен үзгәртү юлы белән төзү турында карарын юллый.

2.2. Яңа төзелгән, үзгәртеп төзелгән, шулай ук төрен үзгәртү юлы белән төзелгән оешма (аерымланган структур бүлекчә) турында гомуми мәгълүматларны алган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән өч көн эчендә ИСТҮ:

а) дәүләт оешмалары буенча:

гомуми мәгълүматларны карап тикшерә һәм, кирәк булганда, дәүләт оешмасын гамәлгә куючыга тәгаенләүче сораулар белән сорату җибәрә, шуннан соң (кирәк булганда) гамәлгә куючы гомуми мәгълүматларны тәгаенли һәм тәгаенләнгән гомуми мәгълүматларны кабат ИСТҮгә җибәрә;

ИСТҮ яңа төзелгән, үзгәртеп төзелгән, шулай ук төрен үзгәртү юлы белән төзелгән оешмадан (аерымланган структур бүлекчәдән) тәгаенләнгән гомуми мәгълүматларны алган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән өч көн эчендә дәүләт оешмасы турында гомуми мәгълүматларны бердәм ведомствоара системага кертә;

б) муниципаль оешмалар буенча:

бердәм ведомствоара система составында «Яңа оешмалар» паспортына гомуми мәгълүматларны кертә.

Тармак министрлыгы (дәүләт комитеты, ведомство) ИСТҮ муниципаль оешма турында гомуми мәгълүматларны керткән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән өч көн эчендә ИСТҮнең рәсми сайтында урнаштырылган бердәм ведомствоара системадан файдаланучылар өчен технологик аңлатмалар белән билгеләнгән тәртиптә, бердәм ведомствоара система составында «Яңа оешмалар» паспортында яңа төзелгән, үзгәртеп төзелгән, шулай ук төрен үзгәртү юлы белән төзелгән оешма (аерымланган структур бүлекчә) хакында гомуми мәгълүматларны карап тикшерә һәм эксперт сыйфатында бердәм ведомствоара системада тиешле тамга ярдәмендә гомуми мәгълүматларның дөреслеген раслый яки расламый.

Кирәк булганда, тармак министрлыгы (дәүләт комитеты, ведомство) муниципаль оешманы гамәлгә куючыга тәгаенләүче сораулар белән сорату җибәрә, шуннан соң (кирәк булганда) гамәлгә куючы гомуми мәгълүматларны һәм (яки) муниципаль оешманы (аерымланган структур бүлекчәне) төзү, үзгәртеп төзү, шулай

ук төрен үзгәртү юлы белән төзү турында җирле үзидарә орган карарын тәгаенли һәм тәгаенләнгән мәгълүматларны кабат ИСТҮгә һәм тармак министрлыгына (дәүләт комитетына, ведомствога) җибәрә. ИСТҮ, кирәк булганда, яңа төзелгән, үзгәртеп төзелгән, шулай ук төрен үзгәртү юлы белән төзелгән оешма (аерымланган структур бүлекчә) хакында гомуми мәгълүматларны кабат алган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән өч көн эчендә гомуми мәгълүматларны бердәм ведомствоара система составында «Яңа оешмалар» паспортында тәгаенли.

Тармак министрлыгы (дәүләт комитеты, ведомство) ИСТҮ муниципаль оешма турында гомуми мәгълүматларны раслаган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән өч көн эчендә бердәм ведомствоара система составында «Яңа оешмалар» паспортында яңа төзелгән, үзгәртеп төзелгән, шулай ук төрен үзгәртү юлы белән төзелгән оешма (аерымланган структур бүлекчә) хакында гомуми мәгълүматларны карап тикшерә һәм эксперт сыйфатында бердәм ведомствоара системада тиешле тамга ярдәмендә гомуми мәгълүматларның дөреслеген раслый яки расламый.

Тармак министрлыгының (дәүләт комитетының, ведомствоның) яңа төзелгән, үзгәртеп төзелгән, шулай ук төрен үзгәртү юлы белән төзелгән оешма (аерымланган структур бүлекчә) турында гомуми мәгълүматларга уңай эксперт бәяләмәсе булганда, дөреслеге расланган очракта, ИСТҮ эш көннәрендә исәпләнгән өч көн эчендә эксперт сыйфатында яңа төзелгән, үзгәртеп төзелгән, шулай ук төрен үзгәртү юлы белән төзелгән оешма (аерымланган структур бүлекчә) хакында гомуми мәгълүматларны бердәм ведомствоара системада тиешле тамга ярдәмендә гомуми мәгълүматларның дөреслеген раслый яки расламый. Кирәк булганда, тармак министрлыгына (дәүләт комитетына, ведомствога) тәгаенләүче сораулар белән сорату җибәрә.

2.3. Гамәлгә куючы ИСТҮ тарафыннан яңа төзелгән, үзгәртеп төзелгән, шулай ук төрен үзгәртү юлы белән төзелгән дәүләт яки муниципаль оешма (аерымланган структур бүлекчә) хакында гомуми мәгълүматлар чыгарылганнан соң эш көннәрендә исәпләнгән өч көн эчендә яңа төзелгән, үзгәртеп төзелгән, шулай ук төрен үзгәртү юлы белән төзелгән оешманың (аерымланган структур бүлекчәнең) тасвирнамәләрен ИСТҮнең рәсми сайтында урнаштырылган бердәм ведомствоара системадан файдаланучылар өчен технологик аңлатмалар белән билгеләнгән тәртиптә бердәм ведомствоара система составындагы оешма паспортында урнаштыра.

Гамәлгә куючы тарафыннан бердәм ведомствоара система составында оешма паспортына кертелә торган яңа төзелгән, үзгәртеп төзелгән, шулай ук төрен үзгәртү юлы белән төзелгән дәүләт яки муниципаль оешма (аерымланган структур бүлекчә) тасвирнамәләренең мәгълүмат составы әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымтада китерелә.

2.4. ИСТҮ эксперт сыйфатында бердәм ведомствоара системада тиешле тамга ярдәмендә кертелгән тасвирнамәләрнең дөреслеген раслый яки расламый. Кирәк булганда, гамәлгә куючыга тәгаенләүче сораулар белән сорату җибәрә.

2.5. Кертелгән тасвирнамәләрнең дөреслеге расланган һәм ИСТҮ экспертизасы тәмамланганнан соң, мәгълүматлар файдалану өчен ачык була.

## 3. ДӘҮЛӘТ ЯКИ МУНИЦИПАЛЬ ОЕШМАЛАРНЫ (АЕРЫМЛАНГАН СТРУКТУР БҮЛЕКЧӘЛӘРНЕ) ЯБУ ТУРЫНДА МӘГЪЛҮМАТ ТАПШЫРУ ТӘРТИБЕ

3.1. Дәүләт яки муниципаль оешма (аерымланган структур бүлекчә) ябылган очракта гамәлгә куючы язма рәвештә, дәүләт хакимияте органының яки җирле үзидарә органының тиешле карары күчермәсен тапшырып, ИСТҮгә, ә муниципаль оешмалар буенча шулай ук тармак министрлыгына (дәүләт комитетына, ведомствога) оешма ябылу турында хәбәр итә.

3.2. ИСТҮ дәүләт яки муниципаль оешма (аерымланган структур бүлекчә) ябылу турында мәгълүматлар алган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән өч көн эчендә бердәм ведомствоара системага тиешле үзгәрешләрне кертә.

## 4. ГАМӘЛДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ЯКИ МУНИЦИПАЛЬ ОЕШМА (АЕРЫМЛАНГАН СТРУКТУР БҮЛЕКЧӘ) ТАСВИРНАМӘЛӘРЕНӘ ҮЗГӘРЕШЛӘР КЕРТҮ ТӘРТИБЕ

4.1. Бердәм ведомствоара системада урнаштырылган оешмалар (аерымланган структур бүлекчәләр) тасвирнамәләре үзгәргәндә, гамәлгә куючы:

ИСТҮ сайтында урнаштырылган бердәм ведомствоара системадан файдаланучылар өчен технологик аңлатмалар белән билгеләнгән тәртиптә бердәм ведомствоара система составында оешма (аерымланган структур бүлекчә) паспортына үзгәрешләр кертә;

кертелгән үзгәрешләрне нигезли торган документлар күчермәләрен урнаштырылган мәгълүматларны тикшерү өчен ИСТҮгә, ә муниципаль оешмалар буенча шулай ук тармак министрлыгына (дәүләт комитетына, ведомствога) җибәрә.

4.2. Тармак министрлыгы (дәүләт комитеты, ведомство) муниципаль оешмалар тасвирнамәләренә үзгәрешләр кертүне нигезли торган документлар күчермәләрен карап тикшерә һәм эксперт сыйфатында бердәм ведомствоара системада тиешле тамга ярдәмендә кертелгән үзгәрешләрнең дөреслеген раслый яки расламый. Кирәк булганда, муниципаль оешманың гамәлгә куючысына тәгаенләүче сораулар белән сорату җибәрә, шуннан соң (кирәк булганда) гамәлгә куючы бердәм ведомствоара система составында тасвирнамәләрне тәгаенли.

4.3. ИСТҮ дәүләт оешмалары тасвирнамәләренә үзгәрешләр кертүне нигезли торган документлар күчермәләрен карап тикшерә, һәм муниципаль оешмалар тасвирнамәләренә гамәлгә куючы керткән үзгәрешләргә тармак министрлыгының (дәүләт комитетының, ведомствоның) уңай эксперт бәяләмәсе булганда дөреслеге расланган очракта эксперт сыйфатында бердәм ведомствоара системада тиешле тамга ярдәмендә кертелгән тасвирнамәләрнең дөреслеген раслый яки расламый. Кирәк булганда гамәлгә куючыга тәгаенләүче сораулар белән сорату җибәрә.

Кертелгән үзгәрешләрнең дөреслеге расланганнан һәм ИСТҮ экспертизасы тәмамланганнан соң, мәгълүматлар файдалану өчен ачык була.

## 5. ТӨЗЕРГӘ ПЛАНЛАШТЫРЫЛА ТОРГАН ДӘҮЛӘТ ҺӘМ МУНИЦИПАЛЬ ОЕШМАЛАРНЫҢ (АЕРЫМЛАНГАН СТРУКТУР БҮЛЕКЧӘЛӘРНЕҢ) ТАСВИРНАМӘЛӘРЕН ТАПШЫРУ ТӘРТИБЕ

5.1. Гамәлгә куючы тарафыннан төзергә планлаштырыла торган дәүләт, муниципаль оешманың (аерымланган структур бүлекчәнең) хезмәт күрсәтүгә бюджет ихтыяҗы нормативын бәяләү турында карар кабул ителгән очракта:

төзергә планлаштырыла торган дәүләт, муниципаль оешманың (аерымланган структур бүлекчәнең) тасвирнамәләре әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымта нигезендә хезмәт күрсәтүгә бюджет ихтыяҗы нормативын бәяләү өчен гамәлгә куючы тарафыннан ИСТҮгә, ә муниципаль оешмалар буенча шулай ук тармак министрлыгына (дәүләт комитетына, ведомствога) җибәрелә;

тармак министрлыгы (дәүләт комитеты, ведомство) төзергә планлаштырыла торган муниципаль оешманың тасвирнамәләрен карап тикшерә, кирәк булганда аларны тәгаенли, аннан соң төзергә планлаштырыла торган муниципаль оешманың тасвирнамәләрен дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә бюджет ихтыяҗы нормативын бәяләү өчен ИСТҮгә җибәрә.

## 6. МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘРНЕҢ ТЫШКЫ ТӨЗЕКЛӘНДЕРҮ ОБЪЕКТЛАРЫ ТАСВИРНАМӘЛӘРЕНӘ ҮЗГӘРЕШЛӘР КЕРТҮ ТӘРТИБЕ

6.1. Әлеге Нигезләмәгә 4 нче кушымтада китерелгән муниципаль берәмлекнең гамәлдәге тышкы төзекләндерү объектлары тасвирнамәләре үзгәргәндә, шулай ук җирле үзидарә органы балансына муниципаль район, шәһәр округы территориясендә урнашкан тышкы төзекләндерүнең яңа объектларын җирле үзидарә орган балансына алганда муниципаль районның, шәһәр округының җирле үзидарә органы:

ИСТҮ сайтында урнаштырылган бердәм ведомствоара системадан файдаланучылар өчен технологик аңлатмалар белән билгеләнгән тәртиптә бердәм ведомствоара система составындагы муниципаль районны төзекләндерү паспортына үзгәрешләр кертә;

урнаштырылган мәгълүматларны тикшерү өчен Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына һәм ИСТҮгә кертелгән үзгәрешләрне нигезли торган документлар күчермәләрен җибәрә.

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы муниципаль берәмлекнең тышкы төзекләндерү объектлары тасвирнамәләренә үзгәрешләр кертүне нигезли торган документлар күчермәләрен карап тикшерә һәм эксперт сыйфатында бердәм ведомствоара системада тиешле тамга ярдәмендә кертелгән тасвирнамәләрнең дөреслеген раслый яки расламый. Кирәк булганда, муниципаль район, шәһәр округының җирле үзидарә органына тәгаенләүче сораулар белән сорату җибәрә, шуннан соң (кирәк булганда) бердәм ведомствоара система составында муниципаль берәмлекнең тышкы төзекләндерү

объектлары тасвирнамәләре тәгаенләнә.

6.2. ИСТҮ муниципаль район, шәһәр округының җирле үзидарә органы тарафыннан тышкы төзекләндерү объектлары тасвирнамәләренә кертелгән үзгәрешләрнең сәбәпләре карап тикшерелә һәм, муниципаль берәмлекнең тышкы төзекләндерү объектлары тасвирнамәләренә муниципаль район, шәһәр округының җирле үзидарә органы керткән үзгәрешләргә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының уңай эксперт бәяләмәсе булганда, дөреслеге расланган очракта эксперт сыйфатында бердәм ведомствоара системада тиешле тамга ярдәмендә кертелгән тасвирнамәләрнең дөреслеген раслый яки расламый.

Кирәк булганда, тәгаенләүче сораулар белән Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына сорату җибәрә.

Кертелгән үзгәрешләрнең дөреслеге расланганнан һәм ИСТҮ экспертизасы тәмамланганнан соң, мәгълүматлар файдалану өчен ачык була.

F:\KARAR\2016\41.docx

Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне планлаштыру һәм мониторинглау буенча мәгълүмат ресурсын формалаштыруның бердәм ведомствоара системасында урнаштырылучы дәүләт, муниципаль учреждениеләр тасвирнамәләрен мониторинглау һәм аларга булышлык күрсәтү тәртибе турында нигезләмәгә 1 нче кушымта

**Яңа төзелгән, үзгәртеп төзелгән, шулай ук төрен үзгәртү юлы белән төзелгән дәүләт һәм муниципаль оешма (аерымланган структур бүлекчә) турында гомуми мәгълүматлар**

Муниципаль район (шәһәр округы) исе-ме________________________________________________________________
______________________________________________________________________

Оешма – юридик затның тулы исеме
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

Оешма – юридик булмаган затның (аерымланган структур бүлекчәнең) тулы исеме [1]
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

| Т/с | Реквизит исеме | Реквизит мәгънәсе |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Эшчәнлек төре [2] | |
| 2. | Ведомствога каравы [3] | |
| 3. | Гамәлгә куючы | |
| 4. | Милек рәвеше [4] | |
| 5. | Оешма төре [5] | |
| 6. | Адресы [6] | |
| | индексы | |
| | торак пункт исеме | |
| | урам | |
| | йорт саны | |
| 7. | Бюджет дәрәҗәсе [7] | |
| 8. | Бюджет классификациясе коды | |
| 9. | ИНН | |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 10. | КПП | |
| 11. | ОКАТО | |
| 12. | Коммуналь хезмәт күрсәтүче исеме | |
| | Су белән тәэмин итү (су үткәргеч) | |
| | Су агызу (үзәкләштерелгән канализация) | |
| | чүп чыгару | |
| | кайнар су белән тәэмин итү | |
| | сыек көнкүреш калдыклары (шакшы сулар чокыры) | |
| | ягып җылыту (сулы) | |
| | электроэнергия | |

Гомуми мәгълүматлар бирүнең нигезләре: төзү, үзгәртеп төзү, төрен үзгәртү юлы белән төзү (кирәклесенең астына сызарга).
Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы/җирле үзидарә органы карары: ________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

Норматив документ күчермәсе теркәлә.

---

[1] Юридик затның аерымланган структур бүлекчәсе турында гомуми мәгълүматларны рәсмиләштергәндә тутырыла.

[2] Мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, яшьләр сәясәте, физкультура һәм спорт, типлаштырылмаган.

[3] Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе, Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнешен һәм сыйфатын тикшерүдә тоту һәм кулланучылар хокукын яклау дәүләт инспекциясе, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты, Татарстан Республикасы Хайваннар дөньясын саклау һәм файдалану идарәсе, җирле үзидарә органы.

[4] Дәүләт, муниципаль.

[5] Автоном, бюджет, казна.

[6] Кайсысының гомуми мәгълүматлары рәсмиләштерүгә карап, юридик зат яки филиалы (аерымланган структур бүлекчә) адресы китерелә.

[7] Татарстан Республикасы; муниципаль район, шәһәр округы; җирле бюджеты.

Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне планлаштыру һәм мониторинглау буенча мәгълүмат ресурсын формалаштыруның бердәм ведомствоара системасында урнаштырылучы дәүләт, муниципаль учреждениеләр тасвирнамәләрен мониторинглау һәм аларга булышлык күрсәтү тәртибе турында нигезләмәгә 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне планлаштыру һәм мониторинглау буенча мәгълүмат ресурсын формалаштыруның бердәм ведомствоара системасы составында гамәлгә куючы тарафыннан оешма паспортына кертелә торган яңа төзелгән, үзгәртеп төзелгән, шулай ук төрен үзгәртү юлы белән төзелгән дәүләт һәм муниципаль оешма (аерымланган структур бүлекчә) тасвирнамәләренең мәгълүмат составы**

Яңа төзелгән, үзгәртеп төзелгән, шулай ук төрен үзгәртү юлы белән төзелгән дәүләт һәм муниципаль оешма (аерымланган структур бүлекчә) тасвирнамәләре Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне планлаштыру һәм мониторинглау буенча мәгълүмат ресурсын формалаштыруның бердәм ведомствоара системасы составында гамәлгә куючы тарафыннан оешма паспортына 1 – 12 таблицалар нигезендә кертелә.

1 таблица. Оешма турында гомуми мәгълүматлар (эшчәнлекнең, оешмаларның бөтен төрләре өчен)

| Реквизит исеме | Реквизит мәгънәсе |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Җитәкче | |
| Телефон | |
| Баш хисапчы | |
| Телефон | |
| Факс | |
| E-mail | |
| Интернеттагы сайт адресы | |
| Оешма төре | 6 – 11 таблицалар нигезендә (эшчәнлек төрләре |

| 1 | 2 |
|---|---|
| | буенча) |
| Оешма рәвеше | 6 – 11 таблицалар нигезендә (эшчәнлек төрләре буенча) |
| Утыру урыннары саны | «Мәдәният» эшчәнлек төре оешмалары өчен |
| Яшел утыртмалар мәйданы, гектар | «Мәдәният» эшчәнлек төре оешмалары – парклар өчен |
| Тулай торактагы койкалар саны | «Мәгариф» эшчәнлек төре оешмалары өчен |
| Оешманың уңайлыклары төре: су белән тәэмин итү, су агызу | 5 таблица нигезендә |
| Оешманың уңайлыклары төре: ягып җылыту | 5 таблица нигезендә |
| Ведомстводан тыш сак булу-булмау | |

2 таблица. Мәйданнар буенча оештыруның төп чараларына тасвирнамә (эшчәнлекнең, оешмаларның барлык төрләре)

| Реквизит исеме | Реквизит мәгънәсе |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Мәйдан саны* | |
| Мәйданны гамәлгә кертү датасы | |
| Мәйданның китү датасы | |
| Бинаның һәм корылманың капитальлек төркеме | 4 таблица нигезендә |
| Мәйданның билгеләнеше | 5 таблица нигезендә |
| Беренче-торгызу бәясе, мең сум | |
| Таушалуы,процент | |
| Калдык бәясе, мең сум | |
| Капиталь төзәтү (дата, чыгымнар, финанслау чыганаклары) | |
| Агымдагы төзәтү (дата, чыгымнар, финанслау чыганаклары) | |
| Трибуналарда утыру урыннары | «Физик культура һәм спорт» эшчәнлек төре оешмалары өчен – 12 таблица нигезендә |
| Мәйданның япмасы төре | «Физик культура һәм спорт» эшчәнлек төре оешмалары өчен – 12 таблица нигезендә |

| 1 | 2 |
|---|---|
| Адресы (торак пункт, урам, йорт номеры) | |
| Гомуми мәйдан, кв.метр** | |
| Ягып җылытыла торган мәйдан, кв.метр | |
| Аренда: | |
| арендалана торган мәйдан, кв.метр | |
| арендага бирелә торган мәйдан, кв.метр | |

* Мәйдан – ул капитальлек төркеме (4 таблица), адресы яки уңайлыклары белән аерылып торган (спорт корылмалары өчен бинаның бер өлеше яки капитальлек төркеме һәм уңайлыклары булмаган ачык мәйдан булырга мөмкин) мөстәкыйль бина.

** СНиП 2.08.02-89 нигезендә җәмгать бинасының гомуми мәйданы барлык катларның суммасы (техник, чардак, цоколь һәм подвал катларын да кертеп) буларак билгеләнә. Антресольләр, башка биналарга күчү юллары, пыяла верандалар, галереяләр һәм балконнар, тамаша заллары һәм башка заллар бинаның гомуми мәйданына кертелергә тиеш.

3 таблица. Транспорт чараларына тасвирнамә

| Автотранспорт чарасы моделе | Автомобильнең төре | Ат көче саны | Чыккан елы | Ел башына үткән юлы, километр | Ел башына таушалуы, процент |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

4 таблица. Биналарның һәм корылмаларның капитальлек төркеме

| Бина төре | Капитальлек төркеме |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Таш, 2,5 – 3,5 кирпеч калынлыгында аеруча капиталь кирпечтән диварлар яки тимербетон яки металл каркас белән кирпеч диварлар, тимербетон яки бетон түшәмнәр белән | 1 |
| 1,5 – 2,5 кирпеч калынлыгында кирпеч диварлар, тимербетон, бетон яки агач түшәмнәр; эре чыгырлы диварлар, тимербетон түшәмнәр белән | 2 |
| Кирпечтән, монолит шлакбетоннан, җиңел шлакблоклардан, кабырчык токымнан диварлар, тимербетон яки бетон түшәмнәр | 3 |

| 1 | 2 |
|---|---|
| Эре панель диварлар, тимербетон түшәмнәр белән | 4 |
| Эре чыгырлы яки Кирпечтән, монолит шлакбетоннан, җиңел шлакблоклардан, кабырчык токымнан диварлар, агач түшәмнәр белән | 5 |
| Катнаш, агач бурап салынган һәм борыслардан ясалган диварлар белән | 6 |
| Эшкәртелмәгән чималдан, җыелма-киртә, күмелгән каркаслы, балчык | 7 |
| Камыш каркаслы һәм бүтән җиңеләйтелгән | 8 |

5 таблица. Эшчәнлекнең барлык төрләренә карата кулланыла торган тасвирнамәләр исемлеге

| Реквизит исеме | Реквизит мәгънәсе |
|---|---|
| Оешманың уңайлыклары төре: су белән тәэмин итү, су агу | кайнар су белән тәэмин ителгән |
| | кайнар су белән тәэмин ителмәгән канализация белән |
| | кайнар су белән тәэмин ителмәгән канализациясез |
| | су алу колонкасы |
| Оешманың уңайлыклары төре: ягып җылыту | җылылык электростанциясе |
| | электр энергиясендә автоном җылылык белән тәэмин ителү |
| | башка төр энергиядә (газ, утын, мазут, ташкүмер) автоном җылылык белән тәэмин ителү |
| Мәйданның билгеләнеше | функциональ бина |
| | административ бина |
| | ашханә |
| | гараж |
| | склад |
| | подвал |
| | котельный |
| | спорт корылмасы* |
| | спорт-сәламәтләндерү комплексы* |
| | спорт клубы* |
| | башкалар |

*Балалар яшүсмерләр спорт мәктәпләре өлешендә «Физик культура һәм спорт» һәм «Мәгариф» эшчәнлек төрләре өчен мәйданнар билгеләнешен сайлау өстәмә рәвештә 12 таблица нигезендә.

6 таблица. Мәдәният оешмалары төрләре һәм рәвешләре

| Оешма төре | Оешма рәвеше |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Дәүләт китапханәсе | милли |
| | Республика балалар |
| | Республика яшүсмерләр |
| | Республика махсус сукырлар өчен |
| Муниципаль китапханә | үзәк |
| | үзәк балалар |
| | шәһәр |
| | шәһәр балалар |
| | авыл |
| | авыл балалар |
| Дәүләт музее | дәүләт тарихи-туган якны өйрәнү |
| | дәүләт сәнгать |
| | музей-тыюлык |
| | мемориаль |
| Муниципаль музей | муниципаль тарихи-туган якны өйрәнү |
| | муниципаль сәнгать |
| | музейлар берләшмәсе |
| Театраль-тамаша оешмасы | дәүләт профессиональ театры |
| | муниципаль профессиональ театр |
| | дәүләт концерт коллективы |
| | муниципаль концерт коллективы |
| | концерт залы, филармония |
| | цирк |
| Дәүләт профессиональ | опера һәм балет театры |
| | драма театры |
| | яшь тамашачы театры |
| | курчак театры |
| Дәүләт концерт коллективы, шул исәптән аерымланган структур бүлекчә | симфоник оркестр |
| | җыр һәм бию ансамбле |
| | фольклор ансамбле |
| | хореография коллективы |
| | халык кораллары оркестры |
| | фольклор музыкасы ансамбле |
| | опера һәм камера музыкасы отделы |
| | эстрада-симфония оркестры |
| | филармония джаз оркестры |
| | кыллы квартет |
| | камера хоры |
| Кинематография оешмалары | кинематография оешмалары |
| Мәдәният һәм ял паркы | мәдәният һәм ял паркы |
| Типлаштырылмаган | типлаштырылмаган мәдәни-агарту оешмалары |

| 1 | 2 |
|---|---|
| мәдәни-агарту оешмалары | |

7 таблица. Физик культура һәм спорт оешмалары төрләре һәм рәвешләре

| Оешма төре | Оешма рәвеше |
|---|---|
| Спорт клубы | спорт әзерлеге үзәге |
| Спорт-сәламәтләндерү комплексы | спорт-сәламәтләндерү комплексы |
| Спорт корылмасы | спорт корылмасы |

8 таблица. Яшьләр сәясәте оешмалары төрләре һәм рәвешләре

| Оешма төре | Оешма рәвеше |
|---|---|
| Ялны оештыру | яшьләр үзәге |
| | яшәү урыны буенча яшүсмерләр клубы |
| Социаль хезмәт күрсәтүне оештыру | балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм үзәге |
| | телефон аша ашыгыч психологик ярдәм үзәге |
| Сәламәтләндерү-ялны оештыру (лагерь) | сәламәтләндерү-ялны оештыру (лагерь) |
| Типлаштырылмаган оешмалар | балаларның һәм яшьләрнең сәламәтләнүен, ялын һәм мәшгульлеген оештыру үзәге |
| | җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (студентлар) берләшмәләре |
| | студентларның хезмәт отрядлары үзәге |
| | Республика яшьләр, инновацион һәм профилактик программалар үзәге |

9 таблица. Мәгариф оешмалары төрләре һәм рәвешләре

| Мәгариф оешмасы төре | Мәгариф оешмасы рәвеше |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Мәктәпкәчә белем бирү оешмасы | мәктәпкәчә мәгариф оешмасы |
| Гомуми белем бирү оешмасы | башлангыч мәктәп |
| | төп мәктәп |
| | урта мәктәп |
| | кадетлар мәктәбе |
| | башлангыч интернат мәктәп |
| | төп интернат мәктәп |
| | урта интернат мәктәп |

| 1 | 2 |
|---|---|
| | интернат мәктәп |
| | шифаханә интернат мәктәп |
| | шифаханә-урман мәктәбе |
| | кичке (сменалап) гомуми белем бирү мәктәбе |
| Һөнәри белем бирү оешмасы | училище |
| | лицей |
| | көллият |
| | техникум |
| Югары белем бирүне оештыру | югары уку йорты |
| Өстәмә белем бирүне оештыру | балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе |
| | сәнәгать-эстетика юнәлешен оештыру |
| | балаларга өстәмә белем бирүне күппрофильле оештыру |
| Балалар йорты | балалар йорты |
| Типлаштырылмаган оешма | типлаштырылмаган оешма |

10 таблица. Социаль хезмәт күрсәтү оешмалары рәвешләре

| | |
|---|---|
| Стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмасы рәвешләре | картлар һәм инвалидлар өчен интернат йорт (пансионат) |
| | картлар һәм инвалидлар өчен махсус интернат йорт |
| | психоневрология интернаты |
| | акыл ягыннан артта калган балалар өчен балалар интернат йорты |
| | физик кимчелекләре булган балалар өчен интернат йорт |
| | балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приют |
| | балигъ булмаганнар өчен социаль-тернәкләндерү үзәге |
| | инвалидларны тернәкләндерү үзәге |
| | билгеле бер тору урыны һәм шөгыле булмаган затлар өчен социаль адаптация үзәге |
| Ярымстационар социаль хезмәт күрсәтү оешмасы рәвешләре | халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплексы үзәге |
| | гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм үзәге |
| | мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәге |
| | сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен социаль тернәкләндерү үзәге |
| Өйдә социаль хезмәт күрсәтү оешмасы рәвешләре | өйдә социаль хезмәт күрсәтү бүлекләре |

11 таблица. Сәламәтлек саклау оешмалары төрләре һәм рәвешләре

| Сәламәтлек саклау оешмасы | Сәламәтлек саклау оешмасы рәвеше |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Дәвалау-профилактикалау медицина оешмалары | ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе |
| | участок хастаханәсе |
| | махсуслашкан хастаханәләр (шул исәптән медицина ярдәме профиле буенча), шулай ук дәүләт һәм муниципаль сәламәтлек саклау системасының махсуслашкан хастаханәләре |
| | бала тудыру йорты |
| | госпиталь |
| | медик-санитария часте, шул исәптән үзәк |
| | шәфкать туташы тәрбиясе йорты (хастаханә) |
| | хоспис |
| | лепрозорий |
| | диспансерлар, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль сәламәтлек саклау системасы диспансерлары |
| | амбулатория, шул исәптән табибларныкы |
| | поликлиникалар (шул исәптән балаларныкы), шулай ук дәүләт һәм муниципаль сәламәтлек саклау системасы поликлиникалары |
| | хатын-кызлар консультациясе |
| | бала йорты, шул исәптән махсуслаштырылган |
| | сөт кухнясы |
| | үзәкләр (шул исәптән балаларныкы), шулай ук дәүләт һәм муниципаль сәламәтлек саклау системасының махсуслаштырылган үзәкләре |
| | ашыгыч медицина ярдәме һәм кан салу медицина оешмалары |
| | шифаханә-курорт оешмалары |
| Аерым типтагы медицина оешмалары | медицина профилактикасы үзәге |
| | фаҗигалар медицинасы үзәге |
| | «Резерв» медицина мобилизация резервлары үзәге |
| | медицина мәгълүмат-аналитика үзәге |
| | медицина биофизика үзәге |
| | хәрби-табиб экспертизасы үзәге |
| | суд-медицина экспертизасы үзәге |
| | медицина-социаль экспертиза бюросы |
| | медицина статистикасы бюросы |
| | патология-анатомия бюросы |
| | суд-медицина экспертизасы бюросы |

| | |
|---|---|
| | клиник-диагностика лабораториясе бюросы |
| | бактериологик лаборатория, шул исәптән туберкулезны диагностикалау буенча |
| | медицина отряды, шул исәптән махсус билгеләнештәге (хәрби округ, флотныкы) |
| Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге тармагында күзәтчелек буенча медицина оешмалары | гигиена һәм эпидемиология үзәкләре |
| | чумага каршы үзәк (станция) |
| | дезинфекция үзәге (станция) |
| | халыкка гигиеник тәрбия бирү үзәге |
| | дәүләт санитар-эпидемиология күзәтчелеге үзәге |

12 таблица. Физик культура һәм спортны оештыру өчен кулланыла торган тасвирнамәләр рәвешләре

| Спорт корылмасы төре | Спорт корылмасы рәвеше һәм зурлыгы, спорт корылмалары бүлмәләре рәвешләре |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Спорт клубы | спорт әзерлеге үзәге |
| Спорт-сәламәтләндерү комплексы<br><br>Спорт корылмасы | ату урыны |
| | тир |
| | ату-ау стенды |
| | 4 җиңел атлетика секторлары булган спорт тубы 190 x 107,6 <*> |
| | 3 җиңел атлетика секторлары булган спорт тубы 190 x 102,7 <*> |
| | 2 җиңел атлетика секторлары булган спорт тубы 190 x 97 <*> |
| | велобаза |
| | ат спорты базасы (конкур кыры, чабу әйләнәсе) |
| | чаңгы базасы |
| | чаңгы стадионы |
| | тау чаңгы трассасы |
| | чаңгыда сикерү өчен трамплин |
| | чаңгыроллер трасса |
| | өстәл уеннары белән шөгыльләнү өчен спорт корылмасы (шахмат, шашка, го) |
| | ишкәкле база |
| | яхт-клуб |
| | җилкәнле (боз көймәсе) станция |
| | махсус япмасыз ачык спорт корылмалары, спорт мәйданнары һәм кырлар |

| 1 | 2 |
|---|---|
| | махсус кушылмалы япмалы ачык спорт корылмалары, спорт мәйданнары һәм кырлар |
| | махсус резинобитум япмалы ачык спорт корылмалары, спорт мәйданнары һәм кырлар |
| | махсус синтетик япмалы ачык спорт корылмалары, спорт мәйданнары һәм кырлар |
| | махсус газон япмалы ачык спорт корылмалары, спорт мәйданнары һәм кырлар |
| | махсус җылытыла торган газон япмалы ачык спорт корылмалары, спорт мәйданнары һәм кырлар |
| | спорт аренасы (стадион) |
| | заллар белән спорт корылмалары |
| | ябык бассейн 50-метрлы ванна<*> |
| | ябык бассейн 25 х 16 м<*> |
| | ябык бассейн 25 х 11 м<*> |
| | ябык бассейн 16,67 х 6 м<*> |
| | ябык бассейн 12,5 х 5 м<*> |
| | ябык бассейн 10 х 6 м<*> |
| | ачык бассейн 50-метрлы ванна<*> |
| | ачык бассейн 25 х 16 м<*> |
| | ачык бассейн 25 х 11 м<*> |
| | ачык бассейн 16,67 х 6 м<*> |
| | җиңел атлетика манежы |
| | футбол манежы |
| | ат манежы |
| | ясалма боз белән спорт корылмасы (ябык) <*> |
| | ясалма боз белән спорт корылмасы (ачык)<*> |
| | туп белән хоккей өчен кыр 118 х 74 м (табигый боз)<*> |
| | алка белән хоккей һәм фигуралы шуу өчен мәйданнар 61 х 30 м (табигый боз) <*> |
| | футбол кыры  104 х 69 м<*> |
| | футбол кыры  90 х 60 м<*> |
| | футбол кыры (башка үлчәмнәр<*>) |
| | спорт залы 72 х 36 м<*> |
| | спорт залы 42 х 24 м<*> |
| | спорт залы 36 х 18 м<*> |
| | спорт залы 30 х 18 м<*> |
| | спор залы 24 х 12 м<*> |
| | спорт залы 18 х 12 м<*> |
| | спорт залы 18 х 9 м<*> |

| 1 | 2 |
|---|---|
| | стандарт булмаган үлчәмдәге спорт залы <*> |
| | спорт корылмаларының административ бинасы |
| | ачык уен мәйданнары |
| | картинг өчен ачык комплекс |
| | картинг өчен ябык мәйдан |
| | тау чаңгысы базасы |
| | ябык ишү бассейны |
| | регби өчен кыр |
| | вело- һәм мотоспорт өчен корылма |
| | мотоузышлар өчен юллар |
| | җиңел атлетика өчен ачык корылма |
| | административ бина |
| | табиб кабинеты |
| | ярдәмче бүлмә |

* Төп мәйданнар мәйданы күрсәтелә, мәсәлән, бассейннардагы бассейн суы көзгесе, ясалма һәм табигый боз белән спорт корылмаларында һәм спорт сарайларында боз аренасы мәйданы, манежлар мәйданы h.б.ш. Калган мәйдан административ биналар составында китерелә.

Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне планлаштыру һәм мониторинглау буенча мәгълүмат ресурсын формалаштыруның бердәм ведомствоара системасында урнаштырылучы дәүләт, муниципаль учреждениеләр тасвирнамәләрен мониторинглау һәм аларга булышлык күрсәтү тәртибе турында нигезләмәгә 3 нче кушымта

**Төзүе планлаштырылган дәүләт һәм муниципаль оешма (аерымланган структур бүлекчә) тасвирнамәләре**

## 1. ЭШЧӘНЛЕКНЕҢ БАРЛЫК ТӨРЛӘРЕ, ОЕШМАЛАРНЫҢ БАРЛЫК ТӨРЛӘРЕ, РӘВЕШЛӘРЕ ӨЧЕН

1 таблица. Төп чараларның тасвирнамәсе

| Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | Күрсәткечнең мәгънәсе |
|---|---|---|
| Ягып җылытыла торган мәйдан, барлыгы | кв.метр | |
| шул исәптән тулай тораклар («Мәгариф» эшчәнлек рәвеше өчен генә) | кв.метр | |
| Гомуми мәйдан*, барлыгы | кв.метр | |
| шул исәптән тулай тораклар («Мәгариф» эшчәнлек рәвеше өчен генә) | кв.метр | |
| Биналарның һәм корылмаларның торгызу бәясе | мең сум | |
| Җиһазларның торгызу бәясе | мең сум | |

* «Физик культура һәм спорт» эшчәнлек рәвеше оешмалары өчен 2 нче кушымтаның 12 таблицасы нигезендә спорт корылмаларыннан чыгып караганда гомуми мәйданны күрсәтергә.

2 таблица. Уңайлыклар рәвеше

| Тасвирнамә исеме | Мәгънәсе |
|---|---|
| Оешманы уңайлаштыру рәвеше: су белән тәэмин итү, су агызу | |
| Оешманы уңайлаштыру рәвеше: ягып җылыту** | |

* Су белән тәэмин итүнең, су агызуның рәвешен күрсәтергә:

кайнар су белән тәэмин ителгән;
кайнар су белән тәэмин ителмәгән, канализация белән;
кайнар су белән тәэмин ителмәгән, канализациясез
су алу колонкасы.
** ягып җылытуның төрен күрсәтергә:
җылылык электростанциясе, төркемгә, кварталга, үз котельнясы;
электр энергиясендә автоном җылылык белән тәэмин ителү;
башка төр энергиядә (газ, утын, мазут, ташкүмер) автоном җылылык белән тәэмии ителү.

3 таблица. Коммуналь хезмәтләр күрсәтүчеләр турында мәгълүмат

| Коммуналь хезмәт исеме | Хезмәтне күрсәтүче исеме |
|---|---|
| Су белән тәэмин итү (су үткәргеч) | |
| Су агызу (үзәкләштерелгән канализация) | |
| Чүп чыгару | |
| Кайнар су белән тәэмин итү | |
| Сыек көнкүреш калдыклары (шакшы сулар чокыры) | |
| Ягып җылыту (сулы) | |
| Электроэнергия | |

4 таблица. Транспорт чараларына тасвирнамә

| Автотранспорт чарасы моделе | Автомобильнең төре | Ат көче саны | Чыккан елы | Ел башына үткән юлы, километр | Ел башына таушалуы, процент |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

## 2. «МӘГАРИФ» ЭШЧӘНЛЕК ТӨРЕ

1 таблица. Күләм күрсәткечләре

| Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | Күрсәткечнең мәгънәсе |
|---|---|---|
| Мәктәп янында интернат булу-булмау* | бар/юк | |
| Тулай торакта урыннар саны, куәте** | берәмлек | |

*Гомуми белем бирү мәктәпләре, кичке мәктәпләр, гомуми төрдәге интернат мәктәпләр, сәламәтләндерү лагерьлары өчен тутырыла.
**Һөнәри белем бирү оешмалары өчен тутырыла.

## 3. «ЯШЬЛӘР СӘЯСӘТЕ» ЭШЧӘНЛЕК ТӨРЕ

1 таблица. Финанс күрсәткечләре

| Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | Күрсәткечнең мәгънәсе |
|---|---|---|
| Эшләүчеләрнең уртача эш хакы | сум | |

2 таблица. Күләм күрсәткечләре

| Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | Күрсәткечнең мәгънәсе |
|---|---|---|
| Эшләүчеләрнең штат саны, шул исәптән уртача исемлектәге | штат берәмлеге | |
| Шөгыльләнүчеләр, хезмәттән файдаланучылар саны | кеше | |
| Бүлекләр (төркем, секцияләр, отрядлар) саны | берәмлек | |
| Лагерьның (турбазаның) эш сменалары саны | берәмлек | |
| Лагерьда (турбазада) I сменада ял итүче балалар саны | кеше | |
| Лагерьда (турбазада) II сменада ял итүче балалар саны | кеше | |
| Лагерьда (турбазада) III сменада ял итүче балалар саны | кеше | |

## 4. «МӘДӘНИЯТ» ЭШЧӘНЛЕК ТӨРЕ

1 таблица. Финанс күрсәткечләре

| Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | Күрсәткечнең мәгънәсе |
|---|---|---|
| Эшләүчеләрнең уртача айлык эш хакы | сум | |
| Гамәлдәге керемнәр (бюджеттан тыш акча) | сум | |

2 таблица. Күләм күрсәткечләре

| Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | Күрсәткечнең мәгънәсе |
|---|---|---|
| Штат саны, шул исәптән уртача исемлектәге | кеше | |
| Театр-тамаша оешмаларында артистларның штат саны, шул исәптән уртача исемлектәге | кеше | |

## 5. «ФИЗИК КУЛЬТУРА ҺӘМ СПОРТ» ЭШЧӘНЛЕК ТӨРЕ

1 таблица. Финанс күрсәткечләре

| Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | Күрсәткечнең мәгънәсе |
|---|---|---|
| Эшләүчеләрнең уртача айлык эш хакы | сум | |
| Гамәлдәге керемнәр (бюджеттан тыш акча) | сум | |

2 таблица. Күләм күрсәткечләре

| Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | Күрсәткеч-нең мәгънәсе | Спорт төре |
|---|---|---|---|
| 1.Хезмәткәрләрнең штат саны (тренерларсыз), шул исәптән уртача исемлектәге | кеше | | |
| 2. Тренерлар составының штат саны, шул исәптән уртача исемлектәге | кеше | | |
| 3. Төркемнәрдә шөгыльләнүчеләр саны | | | |
| спорт-сәламәтләндерү | кеше | | |
| башлангыч әзерлек | кеше | | |
| уку-тренировка | кеше | | |
| спорт камиллеге | кеше | | |
| югары спорт осталыгы | кеше | | |
| 4. Ярышлар саны: | | | |
| шәһәр дәрәҗәсе, | берәмлек | | Х |
| район дәрәҗәсе, | берәмлек | | Х |
| республика дәрәҗәсе | берәмлек | | Х |
| 5. Ярышларда катнашучы спортчылар саны | кеше | | Х |

Искәрмә: 2, 3 пунктлар «Спорт төре» графасында күрсәтелгән һәр спорт төре өчен 3 таблица нигезендә тутырыла.

3 таблица. Спорт төрләре

| Т/с | Спорт төре исеме |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 1 | Авиамодель спорты |
| 2 | Автомобиль спорты |
| 3 | Автомодель спорты |

| 1 | 2 |
|---|---|
| 4 | Айкидо |
| 5 | Академик ишү |
| 6 | Акробатик рок-н-ролл |
| 7 | Альпинизм |
| 8 | Армспорт |
| 9 | Бадминтон |
| 10 | Баскетбол |
| 11 | Биатлон |
| 12 | Бильярд спорты |
| 13 | Бодибилдинг |
| 14 | Бокс |
| 15 | Билбаулы көрәш |
| 16 | Боулинг |
| 17 | Велоспорт – маунтинбайк |
| 18 | Велоспорт – шоссе |
| 19 | Су-мотор спорты |
| 20 | Су полосы |
| 21 | Волейбол |
| 22 | Ирекле көрәш |
| 23 | Көнчыгыш хәрби кара-каршы көрәш |
| 24 | Гандбол |
| 25 | Гирь спорты |
| 26 | Го |
| 27 | Гольф |
| 28 | Тау чаңгысы спорты |
| 29 | Бура спорты |
| 30 | Байдаркаларда һәм  каноэда ишү |
| 31 | Грек-рим көрәше |
| 32 | Дартс |
| 33 | Джиу-джитсу |
| 34 | Дзюдо |
| 35 | Йөрү спорты |
| 36 | Капоэйра |
| 37 | Каратэ |
| 38 | Керлинг |
| 39 | Кикбоксинг |
| 40 | Кинологик спорт |
| 41 | Киокусинкай |
| 42 | Ат  спорты |
| 43 | Тимераякта чабу спорты |
| 44 | Җиңел атлетика |
| 45 | Чаңгыда икеле көрәш |

| 1 | 2 |
|---|---|
| 46 | Чаңгы ярышы |
| 47 | Күптөрле диңгез көрәше |
| 48 | Мотоциклет спорты |
| 49 | Өстәл теннисы |
| 50 | Парашют спорты |
| 51 | Җилкәнле спорт |
| 52 | Пауэрлифтинг |
| 53 | Канат тарту |
| 54 | Йөзү |
| 55 | Планер спорты |
| 56 | Су асты спорты |
| 57 | Полиатлон |
| 58 | Гамәли ату |
| 59 | Суга сикерү |
| 60 | Батутта сикерү |
| 61 | Чаңгыда трамплиннан сикерү |
| 62 | Пулялы ату |
| 63 | Пейнтбол |
| 64 | Радиоспорт |
| 65 | Регби |
| 66 | Кул көрәше |
| 67 | Рус лаптасы |
| 68 | Балык тоту спорты |
| 69 | Самбо |
| 70 | Синхрон йөзү |
| 71 | Тауга менү |
| 72 | Скейтбординг |
| 73 | Сноуборд |
| 74 | Бик җиңел авиация спорты |
| 75 | Спорт акробатикасы |
| 76 | Спорт аэробикасы |
| 77 | Спорт гимнастикасы |
| 78 | Спорт-кулланма этчелек |
| 79 | Спорт ориентлашуы |
| 80 | Спорт туристлыгы |
| 81 | Стендка ату |
| 82 | Стильле каратэ |
| 83 | Арбалеттан ату |
| 84 | Җәядән ату |
| 85 | Суднолар модельләштерү спорты |
| 86 | Тай боксы |
| 87 | Бию спорты |

| 1 | 2 |
|---|---|
| 88 | Теннис |
| 89 | Триатлон |
| 90 | Тхэквондо |
| 91 | Авыр атлетика |
| 92 | Ушу |
| 93 | Фехтовать итү |
| 94 | Тимераякта фигуралы шуу |
| 95 | Фитнес-аэробика |
| 96 | Флорбол |
| 97 | Футбол |
| 98 | Хоккей |
| 99 | Үләндә хоккей |
| 100 | Туплы хоккей |
| 101 | Сәнгатьле гимнастика |
| 102 | Черлидинг |
| 103 | Шахмат |
| 104 | Шашка |
| 105 | Эстетик гимнастика |
| 106 | Спортның хәрби-кулланма төрләре |
| 107 | Спортның хезмәт-кулланма төрләре |

## 6. «СОЦИАЛЬ ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮ» ЭШЧӘНЛЕК ТӨРЕ

1 таблица. Күләм күрсәткечләре

| Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | Күрсәткечнең мәгънәсе |
|---|---|---|
| Муниципаль район, шәһәр округы халкы саны* | кеше | |
| Оешманың куәте: | | |
| ярымстационар бүлек | койка | |
| стационар бүлек | койка | |
| Оешманың бер елга эшләү көннәре саны | көн | |

Искәрмә: халыкка социаль хезмәт күрсәтүнең комплекслы үзәкләре өчен 1 таблица һәрберсе өчен аерым тутырыла.

* Стационар булмаган бүлек өчен.

## 7. ТИПЛАШТЫРЫЛМАГАН ОЕШМАЛАР

1 таблица. Финанс күрсәткечләре

| Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | Күрсәткеч мәгънәсе |
|---|---|---|
| Оешма хезмәткәрләренең уртача айлык эш хакы | сум | |

2 таблица. Күләм күрсәткечләре

| Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | Күрсәткеч мәгънәсе |
|---|---|---|
| Хезмәткәрләрнең штат саны, шул исәптән уртача исемлектәге | кеше | |

Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне планлаштыру һәм мониторинглау буенча мәгълүмат ресурсын формалаштыруның бердәм ведомствоара системасында урнаштырылучы дәүләт, муниципаль учреждениеләр тасвирнамәләрен мониторинглау һәм аларга булышлык күрсәтү тәртибе турында нигезләмәгә 4 нче кушымта

**Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне планлаштыру һәм мониторинглау буенча мәгълүмат ресурсын формалаштыруның бердәм ведомствоара системасы составында районны төзекләндерү паспортына җирлекнең җирле үзидарә органы тарафыннан кертелә торган муниципаль берәмлекнең тышкы төзекләндерү объектлары тасвирнамәсе**

<table>
<tr><th>Т/с</th><th>Тышкы төзекләндерү объекты төре исеме</th><th>Тасвирнамә исеме</th><th>Үлчәү берәмлеге</th></tr>
<tr><td>1</td><td>2</td><td>3</td><td>4</td></tr>
<tr><td rowspan="4">1</td><td rowspan="4">Юл хуҗалыгы</td><td colspan="2">Камилләштерелгән япмалы юлларның, үтү юлларының, мәйданнарның гомуми мәйданы, шул исәптән:</td></tr>
<tr><td>асфальтобетон япмалы</td><td>мең кв.метр</td></tr>
<tr><td>вак таш һәм чуерташ япмалы</td><td>мең кв.метр</td></tr>
<tr><td>тротуарларның гомуми мәйданы</td><td>мең кв.метр</td></tr>
<tr><td>2</td><td>Күпер хуҗалыгы</td><td>Күперләрнең, юлүткәргечләрнең, тоннельләрнең гомуми мәйданы</td><td>кв.метр</td></tr>
<tr><td rowspan="3">3</td><td rowspan="3">Гидротехник корылма</td><td colspan="2">Ярларның гомуми озынлыгы, шул исәптән:</td></tr>
<tr><td>Ясалма утыртмалар белән ныгытылган ярлар һәм дамбаларның гомуми озынлыгы</td><td>метр озынлыгы</td></tr>
<tr><td>Ясалма утыртмаларсыз ныгытылган ярлар һәм</td><td>метр озынлыгы</td></tr>
</table>

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | дамбаларның гомуми озынлыгы | |
| | | Буаларның гомуми озынлыгы | метр озынлыгы |
| 4 | Урамны яктырту | Яктыртылган урамнар, үтү юллары һәм ярларның гомуми озынлыгы | километр |
| 5 | Зират, яшел утыртмалар | Шәһәр читендә яшел утыртмаларның гомуми мәйданы | гектар |
| | | Урамнар һәм ярлар буйлап яшел массив-ларның гомуми озынлыгы | километр |
| | | Зиратлар, биотермик чокырлар, терлек каберлекләренең гомуми мәйданы | гектар |
| | | Су саклау зонасының гомуми мәйданы (җирле үзидарә органнары балансында) | гектаров |
| 6. | Тышкы төзекләндерүнең бүтән объектларының торгызылган бәясе | | мең сум |
| 7. | Ташу канализациясе | | метр озынлыгы |

---